РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Площадь Победы, 4, город Бавлы,
423930

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Җиңү мәйданы, 4, Баулы шәһәре,
423930

Тел.: (85569) 5-29-50, факс: (85569) 5-38-72. E-mail: Bavly.Gorispolkom@tatar.ru,
сайт: www.bavly.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07.07.2025 Баулы шәһәре №2010

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Баулы шәһәрендә яшәүчеләрнең яшәү өчен уңайлы шартларга хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) оештыру һәм уздыру турындагы нигезләмә белән һәм «Транзит» ҖЧҖ мөрәҗәгатенә карап, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Сәйдәшев ур., адресы буенча урнашкан 6А участогын, 16:55:010204:1608 кадастр номерлы, мәйданы 827 кв. м. булган, коммуналь-склад объектлары зонасында «ачык автостоянка өчен» булган җирен «Юл ялын тәэмин итү» җиренә җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш,

архитекту
ра һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча гавами тыңлауларны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (алга таба - гавами тыңлауларны оештыручы) оештыра.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча гавами тыңлаулар үткәрү, 2025 елның 7 июленнән 28 июленә кадәр, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

4. Проект экспозициясен үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Пушкин ур., 25 йорт (3 нче кабинет) Татарстан Республикасы КФҮ ДБУ бинасында 2025 елның 16 июленнән 28 июленә кадәр эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр. Гавами тыңлаулар материаллары белән Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге www.Bavly.tatarstan.ru. рәсми сайтында танышырга була.

Тәкъдимнәр, искәрмәләр 2025 елның 7 июленнән 28 июленә кадәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә һәм (яисә) zempalat.Bavly@tatar.ru электрон почтасы аша кабул ителә.

5. Гавами тыңлауларны оештыручыга, проект буенча гавами тыңлаулар уздыру турында җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә әлеге рөхсәтләр соратып алынган хәбәр җибәрергә.

6. Мөрәҗәгать итүче «Транзит» ҖЧҖ гавами тыңлауларны оештыруны һәм әлеге рөхсәт соралган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын хокук ияләренә җиткерүне техник яктан тәэмин итәргә.

7. Гавами тыңлауларны оештыручыга:

7.1. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча гавами тыңлаулар үткәрүне тәэмин итәргә;

7.2.

Проектлар буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне Татарстан Республикасы КФҮ ДБУ бинасында җиһазландырылган мәгълүмат стендына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (www.bavly.tatarstan.ru) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» вкладкасында «иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар)» вкладкасы астында урнаштырырга.

7.3. Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге www.Bavly.tatarstan.ru рәсми сайтында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» вкладкасында «иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар)» вкладкасы астында урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Сәйдәшев ур., адресы буенча урнашкан, 16:55:010204:1608 кадастр номерлы, мәйданы 827 кв. м. булган, 6А участогын, коммуналь-склад объектлары зонасында «ачык автостоянка өчен» булган җирен «Юл ялын тәэмин итү» җиренә җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты.

7.4. 2025 елның 16 июленнән 2025 елның 28 июленә кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр әлеге карарның 7.3 пунктында күрсәтелгән проект буенча Татарстан Республикасы КФҮ ДБУ (Пушкин ур., 25) бинасында экспозицияләр оештырырга.

7.5. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (www.bavly.tatarstan.ru) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» вкладкасында «Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар)» вкладкасы астында, гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» вкладкасында «Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар)» вкладкасы астында урнаштырырга.

9.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе А. А. Михайловага йөкләргә.

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Соколов